ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Татарстан Фәннәр академиясе президенты итеп Рифкать Миңнеханов сайланды

> 2

ОЛЫ БӘХЕТ

Өчәр малай һәм өчәр кыз тапкан эти-әниләр игезәк бала үстерү серләре белән уртаклашты

> 3

ӨМЕТЛЕ КАРТА

Россиядә әтиләр абруен күтәрүнең тагын бер ысулын тәкъдим итәләр

> 3

БЕРДӘМЛЕК

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 98 (29065) | Чәршәмбе | 12 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТЫНГЫСЫЗ ЯЛ

КАЗАНДА БЕР ТӨРКЕМ КЕШЕ СУ КОЕНГАНДА ЧИР ЭЛӘКТЕРГӘН

Сак бул!

Чир дә иярергә мөмкин! Су коенырга яратучыларны белгечләр шулай дип кисәтә. Җәй башланганнан бирле суда батучылар турында хәвефле хәбәрләр әледән-әле ишетелеп кенә тора. Узган елларда су коенуның тагын бер куркыныч ягы барлыгы ачыкланды. Юдино бистәсендәге «Изумрудный» комлыгында ял иткән бер төркем кеше су коенганда авыру йоктырган. Ул нәрсәсе белән куркыныч? Рөхсәт ителмәгән урыннарда су коенганда тагын нинди чирләр иярергә мөмкин? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда яшәүче Минһаҗевлар гаиләсе өчен узган еллар тынгысыз булган. Шимбә көнне гаиләләре белән Юдино бистәсендәге «Изумрудный» күленә су коенырга барган алар. Якшәмбе иртәсендә исә биш яшьлек кызларының кул-аякларына кызыл тимгелләр чыккан. Кызның әнисе Лилия Минһаҗева сүзләренә караганда, баштарак моңа әллә ни игътибар бирмәгән алар.

– Черки тешләгәндер дип уйладык. Әмма игътибар белән карагач, бу тимгелләр сәер тоелды. Өстәвенә алар арта барды. Шуңа күрә кичекмәстән табибка күрендек. «Церкариаль дерматит» дигән диагноз куйдылар. Бирегә моңарчы да су коенырга йөри идек. Әмма мондый хәлнең күзәтелгәне булмады, – дип аптырый әни кеше.

Минһаҗевларның кызларында гына түгел, ял көнне шушы күлдә су коенган дистәләрчә кешенең тәнендә шундый сәер тимгелләр пәйда булган. Ял көне социаль челтәрләр шундый хәбәрләр белән тулган иде. Барысында да бер сүз: күлдә коенганнан соң тәннәренә кызыл тимгелләр чыккан һәм алар бик нык кычыта. Барысына да «церкариаль дерматит» диагнозы куелган.

Табиб-педиатр, медицина фәннәре кандидаты Илдус Лотфуллин сүзләренә караганда, су коенырга яратучылар арасында очрый торган сезонлы авыру бу. Быел табибка шундый беренче очрак белән 24 майда ук очрашырга туры килгән. Су коенганнан соң шундый хәлгә калган 8 яшьлек малайга ярдәм кирәк булган.

– Әлеге чирне китереп чыгарган паразит күбрәк әкәмтөкәмнәрне, суда йөзеп йөргән үрдәкләрне зарарлый. Шуңа күрә үрдәкләр, акчарлаклар күп йөзгән урыннарда, бигрәк тә камышлы сулыкларда су коенганда аеруча сак булырга кирәк. Су аша ул чир кешегә дә йога ала. Паразитның личинкасы тән тиресенә үтеп керә дә шул урын тимгел кебек кызарып чыга. Церкариаль дерматит үзе артык куркыныч авыру түгел. Бер атна дигәндә юкка чыга. Тәнгә эләккән паразит юкка чыгар алдыннан тимгелләр пәйда була. Аннан соң җитди өзлегүләр күзәтелми, – ди белгеч.

Илдус Лотфуллин сүзләренә караганда, беренче тапкыр авырганда әлеге чир җиңелчә генә узса да, кабат йоктырган очракта хәлләр мөшкелрәк булырга мөмкин. Кешенең температурасы күтәрелә, косу, эч китү кебек билгеләр күзәтелә ала. Чир кешедән кешегә йокмый.

Табиб-педиатр сүзләренә караганда, ял итәргә барган җирдән чир ияртеп кайтмас өчен гади генә кагыйдәләрне истә тоту шарт. Су коенып чыкканнан соң иң элек өйдән алып килгән чиста су белән коенып алырга кирәк. Аннары сөлге белән яхшылап сөртенү зарур. Тәндә бер генә пычрак урын да калмасын.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе әлегә бу очрак буенча берниндн аңлатма бирми. Белгечләр «Изумрудный» күленнән су пробалары алган. Тикшерү нәтиҗәләре әлегә билгесез. Әмма шунысы төгәл билгеле: бу комлык буендагы күл идарә тарафыннан су коену тыелган дип табылган урыннар исемлегендә юк. Әлеге исемлектән аңлашылганча, Татарстанда барлыгы 10 комлык буенда су керү тыела. Белгечләр Казандагы «Түбән елга аръягы», «Локомотив» һәм «Зур Аккош күле» комлыкларында, Нурлат, Мамадыш, Лаеш («Кама диңгезе»), Лениногорск, Бөгелмә, Мөслим, Кама Тамагы районындагы комлыкларда су чисталык таләпләренә җавап бирми дип тапкан.

Табиб-инфекционист Илсөя Закирова сүзләренә караганда, җәйге чорда су коенганда дизентерия, корсак тифы, холера, эчәк инфекциясе дә йоктырырга мөмкин.

– Пычрак суда гепатит та эләктерергә мөмкин. Су коенганда теге яки бу чирне йоктыру өчен авызга бер йотым су керү дә җитә. Эсседә су аша инфекция йоктыру куркынычы бермә-бер арта. Әмма салкын су да ышанычлы түгел. Мисал өчен, ротовирус, норовирус түбән температурада тизрәк үрчи. Шуңа күрә җәй көне су коенганда сак булырга, гади генә гигиена кагыйдәләрен үтәргә кирәк, – ди белгеч.

Сан

Ел башыннан бирле Татарстан сулыкларында **36** кешенең, шул исәптән **3** баланың гомере өзелгән. Шушы вакыт эчендә сулыкларда **44** кешене коткарганнар. Коену сезоны башланганнан бирле исә республика сулыкларында **23** кеше батып үлгән. Шуларның берсе – бала. Ун кешене коткарып калганнар. Татарстан буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белгечләре, җәйге эссегә алданып, сулыкларда уяулыкны югалтмаска өнди. Фаҗигале очракларны булдырмас өчен рөхсәт ителгән урыннарда гына су керергә кирәк, ди алар. «Йөзә белмәсәгез, еракка кермәгез, һава тутырылган матраста да ерак китмәгез. Исерткеч эчемлекләр кулланган килеш су коенмагыз», – диелә министрлык хәбәрендә.

Шуннан арттырмаска

Аучыларга бер ел эчендә 1730 мең баш поши, болан һәм селәүсен атарга рөхсәт итәчәкләр. «2023 елның 1 августыннан 2024 елның 1 августына кадәрге чорда Татарстан Республикасы территориясендә аулау лимитларын раслау турында» указ проектында шул хакта әйтелгән. Документ коррупциягә каршы экспертиза сайтына урнаштырылган.

Исемлектә җәнлекләрнең биш төрен аулау күздә тотылган. Әйтик, республикада 15819 баш поши исәпләнелә. Шулардан 865 баш хайванны (5,47%) ауларга мөмкин булачак. Себер кыр кәҗәләре саны – 15118. Аулау лимиты – 668 (4,42%). Әлеге исемлеккә шулай ук болан (269 баш, аулау лимиты – 5 баш), селәүсен (100 баш, лимит – 3 баш) һәм бурсык (3206, лимит – 189 баш) кергән.

Моннан тыш документта республикадагы ау биләмәләре һәм хуҗалыкларында кыргый хайваннарны (поши) аулау буенча квота билгеләнгән. Узган елда Татарстанда аулау лимиты 1405 баш булган.

Өстәмә миллионнар

Казан метросы икенче тармагының тәүге өлешен («Юлиус Фучик урамы» станциясеннән «Академик Сахаров урамы» станциясенә кадәр) төзүгә өстәмә рәвештә 943,7 миллион сумнан артыграк күләмдә акча җибәреләчәк. Дәүләт сатып алулары порталындагы тендер документларыннан күренгәнчә, моңа Сахаров станциясеннән «ТАССРның 100 еллыгы» станциясенә кадәр сул һәм уң як тоннельләр (100 метр озынлыкта) казу, Сахаров станциясендә вестибюль төзү, җир асты юлын казу техникасын, технологик арбаларны көйләп эшкә җигү кергән.

20 июльдә аукционга йомгак ясала. Эшләрне быел 12 декабрьгә кадәр төгәлләргә кирәк булачак.

Икенче тармакның беренче өлеше 5,75 чакрым озынлыкта булачак. Аңа «Юлиус Фучик урамы», «10 нчы микрорайон», «ТАССРның 100 еллыгы» һәм «Академик Сахаров урамы» станцияләре керәчәк.

tatarstan.ru

Үзәк банкка чакыралар

Мошенниклар кешеләрне алдауның яңа ысулын уйлап тапкан. Үзәк банкның матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, хәзер алар үзләренә ышаныч яулау өчен, электрон почта аша хат язып, Үзәк банкка «шәхсән кабул итүгә» чакыра башлаган.

Чакыру хатлары кешенең исеме һәм атасының исеме белән мөрәҗәгать итүдән башланып китә. Аларга Россия Банкында «шәхсән кабул итү» вакыты һәм банкның төбәктәге чын адресы күрсәтелә. Шул ук вакытта ялган электрон почта адресыннан файдаланыла. Җинаятьчеләрнең әлеге алдашу ысулы чынбарлыкка бик охшап тора.

Мошенниклар «кармагы»на эләкмәс өчен мондый хатларга игътибар итмәскә кирәк. Россия Банкы кешеләрне беркайчан да «шәхси кабул итү»гә чакырмый, хезмәткәрләре, персональ мәгълүматлар һәм банк мәгълүматларын сорап, кешеләргә мөрәҗәгать итми. Берәр сорау килеп туган очракта, Россия Банкының элемтә үзәгенә (8 (800) 300-30-00, мобиль телефон аша – 300) шалтыратып белешергә мөмкин.

Хәерле юл!

Аклы-сарылы бәя

Юл чыгымнары якын арада ук артмагае. Бу көздә Татарстанда таксида йөрү хакы кыйммәтләнәчәк, дип фаразлаганнар. Ул болай да арзан түгел, билгеле. 1 сентябрьдән тармакны җайга салучы яңа канун үз көченә керәчәк. Әнә шул үзгәрешләр, ахыр чиктә, гади халык кесәсенә сугачак, диләр.

Хәер, быелның 1 сентябреннән такси хезмәтенә бәйле яңа кагыйдәләр бер бездә генә түгел, ә ил күләмендә гамәлгә керәчәк. Федераль канун проекты кысасындагы үзгәрешләр билгеле инде. Төбәкләргә аны тулыландырырга мөмкинлек бирделәр. Бу көннәрдә республика дәрәҗәсендә тәкъдим ителгән яңа таләпләр билгеле булды. Канун проектын Татарстан Дәүләт Советының бу атнада узачак чираттагы утырышында карап тикшерерләр дип көтелә. Такси йөртүчеләрне һәм «шашкалы» машинада йөрүчеләрне ни көтә?

Рульдә утыручыларга таләпләр катгыйланачак. Мәсәлән, өч һәм аннан да күбрәк түләнмәгән штрафы булганнар такси хезмәтендә эшли алмаячак. Федераль канун нигезендә, автомобиль ишекләренә «шашка» тамгасы ябыштыру һәм машина башына әфлисун төсендәге ут кую да мәҗбүри булачак. Таксида үзмәшгульләр эшли алачак. ОСАГО полисыннан башка юлга чыгармаячаклар.

Республикада такси базарын 2011 елда ук кабул ителгән канун нигезендә көйлиләр. Бу ел башында узган киңәшмәләрнең берсендә Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин аны камилләштерергә кирәк дигән фикер белдерде. Юлда йөрүчеләрне озак көттермәделәр. Таксистлар арасында иң нык борчу уяткан үзгәреш, мөгаен, машинаның төсенә бәйледер. 1 сентябрьдән республика юлларында фәкать ак яки сары төстәге такси хезмәте машиналары гына калырга мөмкин.

– Ел башында эшсез калгач, такси хезмәтенә күчтем, – ди Казанда яшәүче Радик Хәсәншин. – Моның өчен әллә ни күп кирәкми. Кара төстәге «Киа» машинам бар. Кесә телефонына махсус кушымта йөкләдем дә юлга чыктым. Такси хезмәтендә көненә 4 мең сум тирәсе акча эшлим. Елларда – күбрәк. Өйдә эшсез утырганчы яхшы, әлбәттә. Тик 1 сентябрьдән минем кебекләргә такси хезмәтенә юл ябылырга мөмкин. Халыкка әлеге төр хезмәт күрсәтүче оешмаларның машиналары нигездә ак яки сары төстә. Аларга барыбер. Тик без анда эшләүче куркусыз машина йөртүчеләргә караганда күпкә әдәплерәк йөрибез. «Шашка»лы кайбер ак машиналарның торышы да ташка үлчәрлек. Аларга юлга чыгарга ярый, ә безгә – юк икән.

«Татар-информ»

Узган атнада Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов бу көздә таксида йөрү бәясе кыйммәтләнергә мөмкин икәнен дә әйтте. Ул моны, яңа канун гамәлгә кергәннән соң, такси базарыннан «соры» хезмәт күрсәтүчеләрнең китүе белән аңлатты. Машиналар саны азая икән, димәк, юл хакы да кыйммәтләнәчәк. Такси хезмәте бүген дә әллә ни арзан түгел. Казанда, мәсәлән, кичке якта 10–15 чакрымлык юл өчен 450–500 сум акча түләргә туры килә. Бәяләр тагын да кыйммәтләнсә, ашыгып кая да булса бару алтын бәясенә төшәчәк.

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Үзебездә җитештерелгән машиналарга өстенлек бирергә кирәк. Алар хәзер бөтенләй башка, сыйфатлы. Дәүләт Думасы депутатлары да үзебезнең машиналарда йөрсен. Безнең менә дигән «Москвич», «Лада», «Аурус» машиналары бар бит.

(Дәүләт Думасы утырышында әйткән сүзләре)

ТАТАРСТАНДА – ХАЛЫК САНЫ

Татарстанстат мәгълүматларына караганда, 2023 ел башында республикада 4001625 кеше яшәгән. Аларның 1869027се – ир-ат, 2132598е – хатын-кыз.

ШӘҺӘР ХАЛКЫ – **3071356** КЕШЕ

1413292 >> ир-ат

1658064 >> хатын-кыз

АВЫЛ ХАЛКЫ – **930269** КЕШЕ

455735 >> ир-ат

474534 >> хатын-кыз

Чир көчәйгән

Татарстанда коронавирус йоктыручыларны хастаханәгә салу очраклары янә арткан. 3–9 июль чорында 35 кеше хастаханәгә эләккән. «Реальное время» интернет газетасы хәбәренә караганда, бу сан алдагы атнадагыга караганда дүрттән бер өлешкә зуррак.

Республикада инфекция ияртүчеләрне хастаханәгә озату очракларының ешаюы 19–25 июнь аралыгында да теркәлгән. Ул чагында 40 сырхауны (алдагы атнадагыга караганда 2,2 тапкыр күбрәк) хастаханәгә салырга туры килгән. Шуннан соң 26 июнь – 2 июль чорында мондыйлар саны 30 процентка кимегән – 28 кеше дәвалауга кабул ителгән.

Соңгы мәгълүматларга караганда, пандемия башланганнан бирле Татарстанда COVID-19 йоктыруның барлыгы 206419 очрагы расланган. 203997 кеше савыккан, 2010 сырхау вафат булган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАЙНАРЛЫК

БМОның Бөтендөнья метеорология оешмасы июльнең беренче атнасын дөньядагы һава торышын күзәтүләр тарихындагы иң эссе атна булды дип белдерде. 7 июльдә уртача глобаль температура 17,24 градус тәшкил итте. 2016 елның 16 августында куелган 16,94 градуслык рекорд артта калды. Эсселек меңләгән кешеләрнең үлеменә китерә. Глобаль климат үзгәрешләре күз алдында.

Табигатьтә генә түгел, җәмгыятьтә дә зур үзгәрешләр, мөнәсәбәтләрнең «кайнарлануы» күзәтелә. Бу юллар НАТОның Вильнюстагы тарихи саммиты ачылырга берничә сәгать калгач языла. Саммитның нинди нәтиҗәләр белән тәмамланасын төгәл әйтә алмыйбыз, әмма аның контурлары шәйләнә инде. Төркиядә Президент сайлавының икенче туры алдыннан мин «Ватаным Татарстан»да: «Икенче тур нинди генә нәтиҗә белән төгәлләнмәсен, дөнья сәясәтенең шахмат тактасында төрек гамбиты башлануга китерергә мөмкин», – дип фаразлаган идем. Игътибар итегез: Әрдоган җиңгән очракта да төрек тышкы сәясәтендә борылыш башланачагын фаразладык һәм соңгы көннәр вакыйгалары бу юлларның авторы ялгышмавын дәлилли.

Үткән тәүлекләрдә Әрдоган Зеленский белән очрашты һәм Киев файдасына берничә мөһим йөреш ясады. Иң әһәмиятлесе: Украинаның НАТО составында булуын яклаячагын белдерде. Вильнюс саммиты бу юнәлештә мөһим адымнар ясар, мөгаен. Әнкара Швециянең НАТОга керүенә дә яшел ут кабызырга җыена. Без бу темага, ихтимал, аерым язма багышларбыз, чөнки безнең якын киләчәгебезне билгели торган вакыйгалар төенләнә. Хәзергә Төньяк атлантик альянс очрашуына Россиянең АКШтагы илчесе Антонов сүзләре белән генә бәя бирик: «Мәскәү һәм Көнбатыш мөнәсәбәтләрендәге вазгыять Россия – НАТО каршылыгының иң начар сценариена таба тәгәри», – диде ул.

Вакыйгаларның кайнар эздән баруы бер Россия – НАТО мөнәсәбәтләрендә генә чагылмый. Планетаның барлык почмакларында да социаль киеренкелек арта. Бу уңайдан Көнбатыш үзе яклаган төп принципларның берсе – сүз иреგеннән баш тарту позициясенә басты. Еврокомиссар Тьерри Бретон 25 августтан башлап социаль челтәрләрнең «бәхәсле контент»ны һәм «фетнәгә чакырулар»ны алып ташларга тиеш булачакларын игълан итте. Буйсынмаган челтәрләр бикләнәчәк.

Кытай – Тайвань – Көнбатыш мөнәсәбәтләре традицион өчпочмакка әверелеп бара. Фәләстыйн мәсьәләсе катлаулана һәм шартлау ноктасына якынлаша. АКШ Согуд Гарәбстанын үз ягына аударырга тырыша, гарәпләр каршы түгел, әмма мөһим шартлар куялар. Иран – Америка яшерен сөйләшүләре дәвам итә. Бу мәйданда да американнар Россиягә каршы уен карталарын чыгарып салырга ниятли. Дөньякүләм бөек вакыйгаларның алшартлары әзерләнә һәм, исән булсак, без аларның бөтен авырлыгын үз җилкәбездә татырбыз әле…

Россиядә

ПЕСКОВ ХӘБӘР ИТӘ

Россиянең яңалыклар кырында уңай хәбәрләр дә, хәвефлеләре дә бар. Бу юлы газета хәбәрчесе Путин сүзчесе Песков авызыннан коелган кайбер яңалыкларга күзәтү ясарга булды. Россия икътисадында вазгыять фаразлаганга караганда яхшырак. Әйе, әйе, сум мәтәлчек атты, әмма Кремльдә бу вакыйгада финанс тотрыклылыгына янау күрмиләр. Песковча әйтсәк, «була торган хәл». Аның каравы илдә эшкәртү сәнәгатенең кискен күтәрелеше күзәтелә. Мишустин Екатеринбургка баргач, май аенда эшкәртү тармакларында сәнәгатьнең 12,8 процентлы үсеше турында хәбәр итте. Дөрес, нигездә хәрби-сәнәгать комплексы кискен ыргылыш ясый һәм үзе артыннан чимал тармакларын да ияртә, билгеле. Хәрби техника һәм снарядлар җитештерү өчен күпме металл кирәк булуын чамалыйсыздыр.

Әрдоган соңгы көннәрдә ясаган «ат йөрешләре»ннән Кремльдә канәгать түгелләр, ләкин ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне бозарга җыенмыйлар. Газ хабы проекты һәм башка инвестицияләр үз көчендә кала. Дөресен генә әйткәндә, Мәскәүнең сайлану мөмкинлекләре күп түгел, Әнкара гамәлләре кытыкка тисә һәм авырттырса да, түзми булмый. Мөнәсәбәтләр бозылу Россия файдасына түгел. Ил мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәргә туры килә.

Песков тараткан хәбәрләр арасында берсе мәгълүмат кырында зур дулкынлану тудырды. Июнь фетнәсеннән соң биш көн вакыт үтүгә, Путин Кремльдә Пригожин һәм «Вагнер» командирлары белән өч сәгатьлек очрашу үткәргән. Россиядә зур түнтәрелешкә китерә язган фетнә җитәкчеләренең ил лидеры белән очрашуы бераз сәеррәк яңгырый яңгыравын. Яңалыкның ни өчен ун көннән артык яшереп тотылуы да сораулар тудыра. Әмма иң мөһиме: фетнәчеләр барысы да үзләренең ил лидерына тугрыклы булуларын белдергәннәр һәм Путин аларга эш урыннары да тәкъдим иткән.

«Российская газета»ның телеграм-каналындагы бер яңалык сискәндерә һәм уйлануларга этәрә. Краснодарда билгесез киллер тарафыннан шәһәрнең мобилизация эше буенча җитәкчесе урынбасары Станислав Ржицкий атып үтерелде. Ржицкий элек Украинага ракеталар белән атучы су асты көймәсе командиры булган һәм украиннарның махсус исемлегендә торган. Телеграм-каналлар үтерүнең Украина махсус хезмәтләренең Израиль МОССАДы үрнәгендә үч алуга керешүләре дип фаразлыйлар. Ассызыклыйбыз: бу – рәсми фараз түгел. Әлегә Россиянең Тикшерү комитеты җинаять эше ачып, эшкә керешә генә. Бер нәрсәне искәртәбез: элекке командир бер дә саклык чаралары күрмәгән, киресенчә, мобиль кушымта аша үзенең маршрутын даими рәвештә интернетта элеп барган, шуңа күрә киллерга аны күзәтү һәм үтерү бер кыенлык та тудырмаган. «Яңа нормальлек» шартларында яшәвебезнең бер мисалы бу.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ҖИҢҮ ӨЧЕН КИРӘК

Россия оборона министры Сергей Шойгу Татарстанда урнашкан предприятиеләрдә дәүләт оборона заказының үтәлешен тикшерде.

tatarstan.ru

Министр Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән бергә Чаллының «Ремдизель» акционерлык җәмгыятендә бронетехниканың төрле үрнәкләрен, аерым алганда, броня кабиналы «КамАЗ»лар, «Линза» махсус медицина автомобилен карады. «Хәзер барлык эшләр график буенча, кайберләре графиктан алда бара. Мөмкинлек булса, эш темпын көчәйтергә кирәк», – диде Сергей Шойгу.

– «КАМАЗ»да, Чаллыда эшләүчеләргә рәхмәт әйтәсем килә. Сез нәтиҗәле, әйбәт эшлисез, – диде министр «КАМАЗ» заводында узган киңәшмәдә. – Күп кенә күрсәткечләр буенча быелга дәүләт оборона заказын үтәү графигы буенча алда барабыз. Бу машиналарга ихтыяҗ бар, техниканы төзәтү, карауга ихтыяҗ бар.

Сергей Шойгу хәрби автомобильләрнең махсус хәрби операциядәге ролен билгеләп үтте. Аерым алганда, «КАМАЗ» Россия армиясе өчен бронясы бик нык булган йөк автомобильләре җитештерә. Киңәшмәдә министр Оборона министрлыгының автобронетанклар буенча баш идарәсенә, «КАМАЗ» белән берлектә, махсус хәрби операция зонасында автомобиль техникасын карау-төзәтүгә ярдәм итү буенча эш төркемен булдыру мәсьәләсен карарга кушты. Шойгу шулай ук Оборона министрлыгының бронетранспортерлар паркын яңарту белән кызыксынуын белдерде. «Заманчарак машина эшләргә кирәк. Хәзер вакытта советлар чорындагы иске паркны яңарту белән шөгыльләнәбез», – дип билгеләп үтте министр.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанга килгән өчен Сергей Шойгуга рәхмәт белдерде. Ул республика оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең дәүләт заказын үтәячәкләрен әйтте. Татарстан Рәисе моны иң мөһим дәүләт бурычы дип атады.

Татарстан башкаласында исә Сергей Шойгу Рөстәм Миңнеханов белән Казан вертолет заводын карады. Биредә аларга «Ансат» вертолетларын һәм Ми-8 хәрби-транспорт вертолетының төрле модификацияләрен җитештерү турында сөйләделәр. Моннан тыш оборона министры һәм Татарстан Рәисе Казан оптика-механика заводына бардылар. Әлеге предприятие көндезге күзәтү оптикасын, төнге күзәтү приборларын, разведка өчен тепловизорлар җитештерә. Шулай ук Сергей Шойгуга модернизацияләнгән Ми-24 вертолетын күрсәттеләр.

Соңыннан оборона министры Татарстан Рәисе белән бергә Ту-160 стратегик ракета йөрткечләр җитештерүче Горбунов исемендәге Казан авиация заводында булды. Быел Коралы Көчләргә 2 яңа һәм 2 модернизацияләнгән Ту-160 ракета йөрткеч тапшырылачак. Дәүләт оборона заказы нигезендә тагын 2 Ту-160 җитештерелә.

Медаль саныйлар

Казанда Сбербанкиада башланды. 14 нче мәртәбә оештырылучы әлеге чара Татарстан башкаласында өченче тапкыр уза. Ачылу тантанасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, «Сбербанк» президенты, идарә рәисе Герман Греф һәм Россия Хоккей федерациясе президенты Владислав Третьяк катнашты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бүгенге шартларда Россиядә зур спорт ярышлары уздыру бик кирәк.

– Моннан ун ел элек бу көннәрдә Казанда яхшы итеп Универсиада уздырдык. Безгә мондый зур спорт чаралары кирәк. Бу бит үзе бер Олимпиада кебек. Ярышны уздыру урыны итеп Казанны сайлаганыгыз һәм бирегә спорт рухы алып килгәнегез өчен рәхмәт, – диде Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, «Сбербанк» – Татарстанның стратегик партнеры.

– Сбербанкиаданы кабул итү безнең өчен зур мәртәбә. «Сбербанк» командасының бердәм корпоратив рухы барлыгын, аларның ничек зур үсеш алуын күрәбез. Мин сезгә чәчәк атуыгызны, спорт уңышлары һәм Казанда матур көннәр кичерүегезне телим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

14 нче мәртәбә оештырылучы әлеге зур чара Казанда 2012 һәм 2017 елларда узган иде инде. Соңгы 4 елда исә пандемия аркасында Сбербанкиада булмады. «Минемчә, кешеләр аралашуны, спортны, бәйрәмне бик сагынды. Ниһаять, бу искиткеч шәһәрдә, искиткеч республикада, искиткеч илдә бергә җыелырга насыйп булды. Илебездәге иң төп компанияләрнең берсендәге команданың тагын да көчлерәк, бердәмрәк, яңа бурычлар үтәргә, сынауларга әзер буласын көтәбез. Төп нәтиҗә әнә шул булачак», – диде Герман Греф.

14 июльгә кадәр узачак ярышта Сбер төркеменә керүче оешмалардан 18 командада 3 меңләп кеше чыгыш ясый. Алар арасында хәтта Һиндстаннан килүчеләр дә бар. Алар спортның 10 төрендә: йөгерү, йөзү, теннис, мини-футбол, волейбол, баскетбол, шахмат, өстәл теннисы, бадминтон, кроссфит буенча ярышачак. Өч көндә 49 комплект медаль үз ияләрен табачак.

ПРЕЗИДЕНТ САЙЛАНДЫ

Татарстан Фәннәр академиясе президенты итеп бертавыштан Рифкать Миңнеханов сайланды. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашында узган Академиянең гомуми җыелышында Вячеслав Алемасов исемендәге Дәүләт премиясе ияләрен дә бүләкләделәр.

Фәннәр академиясенең гамәлдәге президенты, Дәүләт Советы депутаты Мәгъзүм Сәлахов искә төшереп үткәнчә, 23 июльдә Академиянең 13 хакыйкый әгъзасы (академиклары) һәм 15 мөхбир-әгъзасы сайланды. Хакыйкый әгъза булучылар арасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ директоры Рифкать Миңнеханов һәм башкалар бар иде. Кичәге җыелышта дипломнар тапшырганда Мәгъзүм Сәлахов аларны фәнни эшчәнлектәге уңышлары белән котлап, Татарстанның социаль-икътисадый һәм фәнни үсешенә лаеклы өлеш кертәчәкләренә ышаныч белдерде.

Төп вакыйга исә Фәннәр академиясе президентын сайлау булды. Бу вазыйфага бертавыштан Рифкать Миңнехановны сайладылар. Ул – техник фәннәр докторы, профессор, 2016 елдан бирле Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы. Мәгълүмати иминлек, юл хәрәкәте иминлеге һәм акыллы транспорт системалары өлкәсендә белгеч. 190 фәнни эш, шул исәптән 3 монография, 6 авторлык шаһәдәтнамәсе авторы. Рифкать Миңнеханов 1999–2016 елларда Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе белән җитәкчелек итте. Соңгы елларда «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ директоры вазыйфасын башкарды.

tatarstan.ru

Фәрит Мөхәммәтшин Фәннәр академиясе президенты вазыйфасында күпьеллык эшчәнлеге өчен Мәгъзүм Сәлаховка рәхмәт сүзләре җиткерде. Шулай ук коллегаларын яңа сайланган президентка ярдәм итәргә чакырды. Рифкать Миңнехановка уңышлар теләп, аның сайлануы Фәннәр академиясенә «яңа сулыш» алып киләсенә ышаныч белдерде. «Республика фәнне үстерүгә һәрвакыт зур игътибар бирде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Фәнни фикерсез, фәнни алымнарсыз, инновацияләрсез һәм алдынгы технологияләрсез Татарстан кебек күп милләтле, күп мәдәниятле, күп телле, күп кырлы икътисадлы республикада тормыш эшчәнлеген оештыру җиңел түгел». Парламент башлыгы Фәннәр академиясенең уңышлы эшләвен ассызыклады, әмма аерым игътибар таләп итүче мәсьәләләр дә булуын искәртте. Аларның иң мөһиме – чит ил эшләнмәләренә бәйлелектән арынып, аларны үзебездә булдыру.

Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында бүләкләү тантанасы да узды. Июль аенда Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы академигы, танылган галим, Казанның җылылык энергетикасы һәм реактив двигательләр төзү буенча фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе Вячеслав Алемасовның тууына 100 ел тулу билгеләп үтелә. Гадәттәгечә, нәкъ менә шушы вакытта аның исемендәге Дәүләт премияләре тапшырыла. Премия инженерлык фәннәре өлкәсендә фәнни казанышларга ирешкән яшь галимнәргә бирелә. Быел аңа техник фәннәр кандидатлары – «Газпром трансгаз Казань» инженеры Рәүф Сабиров, КНИТУ-КАИ өлкән укытучысы Алия Сәйфетдинова һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты доценты Данил Сабирҗанов лаек булды.

КИРПЕЧНЕҢ ҖАНЫ ЮК

Борчыган мәсьәлә

Мәдәни мохитне төзекләндерелгән диварлар түгел, кешеләр тудыра. Хөкүмәт йортында узган брифингта бу сүзләр берничә тапкыр яңгырады. Билгеле, утын ягыла торган авыл клубларын энтузиастлар гына җылыта алмас. Шуңа да мәдәният дөньясында заманча шартлар тудыруны кадрлар мәсьәләсе белән бергә карарга кирәк.

Кукмарадан үрнәк ал

Республикада «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга багышланган очрашуда Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова чыгыш ясады. Әлеге проект кысасында планлаштырылган һәм акча бүлеп бирелгән эшләрнең күпмесе эшләнгән, никадәр эшлисе бар – саннар телендә әнә шуларны сөйләде. Ирада Әюпова сүзләренә караганда, быел 39 мәдәният оешмасы заманча җиһазлар белән баетылачак, 34 объектта төзекләндерү эшләре башкарылачак. Болар барысы да «Мәдәни мохит» төбәк проекты кысасында эшләнә.

– Быел әлеге проектны тормышка ашыру өчен 1077948300 сум бүленде. Бу акчага өч муниципаль китапханә төзеләчәк, Түбән Каманың «2 нче номерлы балалар музыка мәктәбе»ндә капиталь ремонт булачак, – дип сөйләде ул. – Моннан тыш, «Мәдәният» проекты кысасында Биектау һәм Чаллыдагы туган якны өйрәнү музейлары, Сарманның Бөек Ватан сугышы музее, Чирмешәндәге мемориаль үзәк, Татарстанның Милли музее, шулай ук Тинчурин театры техник җиһазлар белән баетылачак.



«Татар-информ»

Шулай ук Биектау районының Урта Алат авылында, Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында, Балык Бистәсе районының Олы Елга авылында, Кукмара районының Байлангар, Күкшер һәм Ядегәр авылларында мәдәният йортларында капиталь ремонт булачак. Кукмаралылардан көнләшмәгез, Ирада Әюпова сүзләренә ышансаң, алар төрле яклап акча җәлеп итә белә, анда төпләнеп калучы яшьләр дә чагыштырмача күбрәк.

– Бөтен мөмкинлектән файдалана белә алар. Илкүләм проектлар аша да, авыл хуҗалыгы тармагындагы программалар аша да – кыскасы, комплекслы эш башкаралар, – диде ул.

Сан

2023 елда Татарстанда «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру өчен **1103338300** сум акча бүлеп бирелгән. Шуның **692224500** сумы – федераль акча булса, **411113800** сумы – республика бюджетыннан.

Кеше кирәк

Бина булу – бер нәрсә, анда эшләргә кеше дә кирәк бит әле. Бигрәк тә авыллардагы мәдәният учагын сүндерми саклау – зур проблема. Боларның барысын да колачлый торган «Иҗади кешеләр» төбәк проектына 2023 елга 23,5 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелгән.

– Бу проект кысасында дүрт меңгә якын белгечнең квалификациясен арттыру күз уңында тотыла. Алар илнең иң яхшы уку йортларында белем алачак. Моннан тыш, 2023 елда авыл мәдәният йортларында эшләүче 40 кешегә 50шәр мең сум күләмендәге акча бирелде, – дип сөйләде бу җәһәттән Ирада Әюпова.

Кадрлар мәсьәләсенә җан кертер өчен Россия Дәүләт Думасының Мәдәният комитеты рәисе Елена Ямпольская «Земский работник культуры» программасын булдырырга тәкъдим итте.

– Безнең бу хакта беренче кат кына әйтүебез түгел. «Земский учитель», «Земский доктор»га охшаш программа булдырырга кирәк. Әгәр без теге яисә бу мәдәният учреждениесен төзекләндердек дип сөйлибез икән, анда эшләргә кешесен дә табыйк. Мәдәният ул – диварлар түгел, мәдәният ул – беренче чиратта, кешеләр, – диде ул видеоконференция элемтәсе аша.

Йомгак урынына

Журналистлар белән очрашу ахырында Ирада ӘЮПОВА Татарстанның мәдәният тармагындагы төп өч проблеманы атады.

1. Кадрлар. «Мәдәният өлкәсендә битараф кешеләр эшли алмый. Үз эшен, үзе белән эшләүче кешеләрне үлеп яраткан белгечләр кирәк».

2. Һәр мәдәният учреждениесенең функциональ билгеләнешен яңадан карау. «Бу мәсьәләне федераль дәрәҗәдә карыйлар, системага салып эшләмәсәк, булдырып чыга торган түгел».

3. Һәркем файдалана алырлык мохит булдыру. «Һәркем тигез булырга тиеш. Безгә барлык кешеләр өчен дә эшләргә кирәк».

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ӘТИ КИРӘК

Мөнәсәбәт

Әтиләрнең акчасы артачак. Россия Дәүләт Думасында гаилә башлыкларының абруен арттыруның яңа ысулын тәкъдим иткәннәр. Анысы да монысы: ил күләмендә «Әтиләр картасы»н гамәлгә кертмәкчеләр. Андагы акчаны фәкать бала тәрбияләүче көчле затлар гына туздыра алачак ди. Бүгенге әти кем ул? Бу сорауга җавапны «ВТ» хәбәрчесе эзләде.

Таңсылу Галимова

Яңалыкны Россия Дәүләт Думасы вице-спикеры, ике бала әтисе Борис Чернышев тәкъдим иткән. Ул бу хактагы уй-фикерләрен илнең хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяковка юллаган да инде. Яңалык яклау тапкан очракта, илдә «Әтиләр картасы» барлыкка киләчәк. Ул хәзер гамәлдә булган «Пушкин картасы»на охшаш булачак ди. Ягъни картадагы акчаны үзең теләгәнчә туздырырга ярамый.

– Әтиләр һәм балалар бергә рәхәтләнеп вакыт үткәрә алсын өчен, тиешле шартлар тудырырга кирәк, – дигән Борис Чернышев. – Югыйсә илдә балаларны әниләр генә тәрбияли дигән фикер бар.

Уртак ял хакы да билгеле. Депутат «Әтиләр картасы»на ай саен һәр балага 2 мең сум акча салып барырга киңәш иткән. Гаилә башлыгы балалар белән кино, зоопарк яки кафеда йөргән арада әниләр «иркенләп ял итәчәк» дип тә өстәгән Борис Чернышев. Менә шундый замана.

– Әтиләр балалары белән күбрәк вакыт үткәрсен өчен, аларны акча белән кызыктырырга туры килүе начар, әлбәттә. Бу очраклы гына туган тәкъдим түгел. Утсыз төтен булмый, – ди «Татарстанның күпбалалы әтиләре» төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Артем Кузнецов. – Ничек кенә булмасын, мин мондый картаны гамәлгә кертүне хуплыйм. Чөнки гаиләдә әти тәрбиясе бик мөһим. Югыйсә бүген, кем тапкан – шул үстерсен, дигәндәй, әни бала тәрбияли, ә әти гаиләне туендыра, дип саныйлар. Бу дөрес түгел. Кызмы ул, ир баламы – аңа әти игътибары кирәк. Тагын бер авырткан җир: хәзер әтиләрнең генә түгел, әниләрнең дә баласына вакыты юк. Моңа бәйле тикшерү нәтиҗәләре дә бар. Белгечләр әти-әниләрдән: «Балагыз белән күпме вакыт бергә үткәрәсез?» – дип сорашкан. Дөнья күләмендә Россия әлеге күрсәткеч буенча 80 нче баскычтан да арттарак калган. Статистика мәгълүматларына ышансаң, без балалар белән тәүлегенә берничә минут кына сөйләшәбез. Сүз «Ашарга утыр», «Дәресеңне әзерләдеңме?» кебек көндәлек сораулар турында түгел, ә нәкъ менә күзгә-күз карап аралашу, баланың уй-фикерләрен сорашу турында бара. Бүген әти-әниләр үзләре дә телефонга чумды. Гаиләдә аралашу юк дәрәҗәсендә. «Әтиләр картасы» балага якынрак булырга ярдәм итәчәк дип саныйм.

Күпбалалы әтиләр оешмасы җитәкчесе фикеренчә, баланы акча салынган картадан башка да тәрбияләп була анысы.

– Мәсәлән, кичләрен өйдә бергә җыелышып «лото» уйнарга яки кино карарга мөмкин. Мин балаларым белән бергә мультфильмнар карарга яратам. Әле яңа гына барыбызга да таныш булган тычкан белән мәче турындагы мультфильмны карадык. «Каһарманнарның кайсы уңай, ә кайсы тискәре?» – дип сорыйм балалардан. «Мәче начар, ул гел тычканны кыерсыта», – диләр. Югыйсә тычкан беренче булып үзе этлек эшли бит. Мультфильмнан соң озак кына үз-үзеңне дөрес тоту турында фикер алыштык. Баланы: «Егылгансың икән, тор, елап ятма», – дип түгел, ә әнә шулай сөйләшеп тәрбияләргә кирәк, – ди Артем Кузнецов.

«Бәләкәч» әниләр берләшмәсе җитәкчесе Нәзилә Сафина әйтүенчә, бала тәрбияләүче гаиләләрдә акчаның бер тиене дә артык түгел.

– Яшь әни буларак, яңалыкны хуплыйм. Әмма акча әтиләргә генә дип, чик куймасалар да ярар иде. Әниләр балага ай саен ала торган пособие дә, ана капиталы да гаиләдә уртак бит. Ә ни өчен әти булган өчен генә аңа аерым акча түләргә? Абруйны бернинди акчага да сатып алып булмый. Гаиләдә айга бер-ике тапкыр киногa алып барып туңдырма ашатучы ир-ат түгел, ә җил-давыллардан саклаучы канат, терәк кирәк, – ди Нәзилә Сафина.

Чүпрәле районының Шланга авылында яшәүче Кәримуллиннар гаиләсендә бар шундый ныклы канат. Шулай булмаса, бер ояда биш бала үстерә алырлар идемени?! Бу көннәрдә ишле гаиләнең шатлыклы көннәре. Яраткан әниләренә Татарстанның «Ана даны» медале бирелүе билгеле булган.

– Тормыш иптәшем Айрат гомер буе йөк машинасында эшли. Шуңа күрә күп вакыты юлда үтә. Гаиләбездә ул – тормыш тоткасы. Балалар да, мин дә аңа бик рәхмәтле. Төпчекләребез: «Әти кайтамы?» – дип, тәрәзәдән карап кына торалар, – ди биш бала әнисе Фәния Кәримуллина. – Мин төрле эштә хезмәт иттем. Балалар күп булгач, хатын-кызга өйдәге эш тә җитәрлек. Бакчабыз зур, теплицалар гына да икәү. Кирәкле бөтен яшелчә, җиләк-җимешне үзебез үстерәбез. Балалар – төп ярдәмчеләребез.

Дүрт кыз һәм бер ул тәрбияли Кәримуллиннар.

– Олы кызыбыз Эльза Камчаткада яши, хастаханәдә программист булып эшли. Икенче кызыбыз Ландыш та еракта – Магаданда. Ул һөнәре буенча стюардесса, әле яңа гына фармацевт дипломы алды. Өченче кызыбыз Ләйсән Казанда яши, чәчтарашка укыды. Төпчекләребез үзебезнең янда. Айгөл былтыр тугызынчы сыйныфны «дүртле», «бишле» билгеләренә бетерде. Мәктәптә укуын дәвам итәчәк. Унберенче сыйныфтан соң IT юнәлеше буенча китәргә хыяллана. Данил да дүртенче сыйныфны яхшы билгеләргә генә тәмамлады, – ди әни кеше.

Бар яктан да үрнәк, көчле әтиләре янында балалар да бәхетле, ди Фәния Кәримуллина.

– Балаларны мәҗбүр итеп тәрбияләмибез. Бу укуларына да, булачак һөнәр сайлауларына да кагыла. Әнә тугызынчы сыйныфны бетергән кызымны бик тә шәфкать туташы итеп күрәсем килә дә, әмма аның үз теләге. Аларга хәлдән килгән кадәр ярдәм итеп торачакбыз. Хәер, алар үзләре хәзер булышучылар инде. Өлкән кызларым, читтә булсалар да, энесе-сеңелләренә гел ярдәм итеп торалар. Безне диңгез буена ял итәргә дә алып баралар. Медаль биргәч, балалар бик сөенде. Горурланып: «Безнең әни бит ул», – диештеләр. Мин исә гаиләм өчен сөендем. Миңа бирелгән зур бүләк артында әтиебезнең дә бәяләп бетергесез тырышлыгы ята, – ди Фәния апа.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Яшәеш

Тажетдиновларның гаилә архивыннан

БЕРЬЮЛЫ – ӨЧ БӘХЕТ!

Мин бүген әни булдым, әни! Беренче тапкыр әни булучылар әнә шулай дип сөенә. Әгәр инде берьюлы өч бәби алып кайтсаң, күңелдә нинди хисләр булганын күз алдына да китереп булмый. Шушы көннәрдә РКБда өч игезәк малай дөньяга аваз салды. 2023 елда Татарстанда беренче очрак бу. Биредә 5 гаиләдә туган игезәкләр дә өйләренә кайтуны көтеп ята.

Әниләре рөхсәт итмәгәч, өч игезәк малайлар турында ныклап белешә алмадык. Шунысы билгеле: малайлар 2500, 2370, 2230 грамм авырлыкта туган. Әлегә аларны ныгысыннар дип реанимация бүлегенә күчергәннәр. Әниләре исә кесарев кисеменнән соң хәл җыя. Малайлар өйләренә бераз соңрак кайтачак.

Өч бала үстерү җиңелме? Без бу сорауларны берьюлы өчәр малай һәм өчәр кыз тапкан әниләргә бирдек. Алар сабыйлары турында бик шатланып, горурланып сөйли.

Балтач районының Куныр авылында яшәүче Гөлназ Шакирҗановнаның уланнарына 4 яшь инде. Кызлары Нәзилә, уллары Ильяс янына тагын бер бала алып кайтырга ниятли алар. Аллаһы Тәгалә исә өч ул белән сөендерә.

– УЗИга баргач, табиб, монда өч бала, диде. Телсез калдым. Ул, тагын юкмы икән, карыйк әле, ди. Шушылары җитәр, дигәнем генә истә. Табиб яныннан чыккач, иремә бу хәбәрне авыз ачып әйтә алмый интектем. Өч бармагымны күрсәтеп тик торам. Аңламый бала бит, ул да телсез калды. Хәзер менә уйлап куям: бигрәк каушаганбыз инде. Бәхет бит ул – сабыйлар, – дип сөйли Гөлназ. – Хәзер мин шулкадәр сөенәм. Бу балалар бөтенләй башка төрле. Белмим, миңа гына шулай тоеладырмы, олы сабыйларым белән чагыштырып карыйм да алар бердәмрәк булып күренәләр. Шул бердәмлекнең көчен белсәгез иде. Берсе авырып, калган икесен бакчага илтәм икән, өйдә калганы тегеләрне юксына башлый. Аерым тора алмыйлар. Бер-берсен яклыйлар. Сүз дә әйтеп булмый. Бик тә туган җанлы булып үсәләр.

Табиб беренче УЗИ узганда малайларның нык ябышып, әниләренең карынында берегеп ятуларына игътибар итә. Әле 4 кенә яшь булса да, эш ярата икән алар.

– Каенатам гына исән түгел. Шушы малайларга карыйм да, их, әти исән булса, нишләп бетәр иделәр икән, дим. Мәш килерләр иде. Бабалары гына иртә китте шул. Шөкер, әниебез бар. Улларыбыз барыбызны да ярата. Аларның сөйләшүләре дә башка инде. Әтием, әнием, абыем, апам, дип кенә торалар. Кечкенәдән ныклы тәрбия дә кирәк. Әни ничек өйрәтсә, балалар шундый була дип уйлыйм. Улларым болыннан чәчәк җыеп, йөгереп яныма кайтуга, гөлләмәне икегә аерам да, әбиләренә бүләк итәрем. Белеп үссеннәр, – ди Гөлназ. – Өч бала үстерү өчен, сабырлык, янәшәңдәгеләрнең аңлый белүе кирәк. Өч баланы тар фатирда үстереп булмас иде. Алар өчен йорт яхшы. Ул сабыйларга иркенлек кирәк. Мин өч бәби тапкач, өзлектем, дип әйтә алмыйм. Киресенчә, шушы малайлардан соң яшәреп киткәндәй булдым. Чәчләрем кабат үсте, тырнакларым ныгыды. Үземне бик яхшы хис иттем. Бала карауны авыр эш итеп кабул итмим. Алар яратуны аңлый. Әнә үскәннәре сизелми дә. Инде киләчәктә үзебезгә игелекле сабыйлар үстерәсе иде. Аллаһы Тәгалә биш баламның да гомерен, сәламәтлеген бирсен!

Узган ел Баулы районында яшәүче Алинә һәм Радик Тажетдиновлар гаиләсендә берьюлы өч кыз дөньяга килде. Олы уллары Шамилгә тиздән биш яшь тула инде. Ә менә сеңелләренең бер айдан туган көннәрен уздырырга әзерләнә.

– Шамилнең үскәнен белми дә калдык. Үзебез дә бала идек әле ул чакта. Бергә үстек, – ди 24 яшьлек Алинә. – Ралинә белән Әминә бер-берсенә бик охшаган. Камиләбез исә арада иң зурысы. Өчесе дә бик шук. Ятып торган чакларында миңа тынычрак иде. Хәзер тотынып торып басалар, йөриләр дә. Эш арта инде аннары. Карап кына өлгер.

Алинә белән Радик кызларын үзләре карыйлар. Ире эштән кайткач булыша икән. Әти-әниләрен бик борчырга тырышмыйлар. Барасы җир булганда гына сабыйларны калдырып торабыз, диләр.

– Балаларыбызны үзебез өчен таптык, үзебез үстерәбез. Хәтта дәүләттән ниндидер ярдәм дә сорамадык. Балалар тугач, район хакимиятеннән 3 мең сумлык сертификат биргәннәр иде. Шуны да куллана алмадык, мәшәкатьләр белән югалттык без аны. Балаларга бердәм пособие алып булмасмы дип барган идек, анысы да чыкмады. Дәүләттән өч балага ай саен берәр мең сум акча түлиләр. Ирем эшләп тора. Шул акчага яшибез, – ди Алинә. – Ирем белән тагын бер малай алып кайтырбыз дип торабыз әле. Кем белә, бәлки, игезәкләр дә булыр. Өчәү булса да яхшы. Бала – бәхетнең иң зурысы.

Алинә өч бала тапкан әниләргә киңәшен дә бирә.

– Тормышны яратып, сабыйларны сөеп яшәгез. Вакыт шулкадәр тиз уза. Әле яңа гына бәби алып кайткан идем. Инде тупылдап торган, шапылдатып сөярлек кызларым үсеп килә. Яратуыңны кызганмаска кирәк. Балалар бит аны сизә, – ди Алинә. – Кайберәүләр бәбидән соң стресс кичерәбез, депрессия безнең, диләр. Минем алай үземне уйлап, чирләрне барлап утырырга вакытым булмады. Нинди депрессия булсын инде ул бала табу?! Хатын-кыз үзен үзгәртергә, ана вазыйфасына күчәргә тиеш. Менә шуннан соң бар да җайлана.

Гөлгенә ШИҺАПОВА



КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының эчке сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы **Мостафин** Данил Мәхмүт улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге башлыгы урынбасары, эчке хезмәт подполковнигы **Костромин** Максим Александровичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Нургалиев** Рамил Ришат улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең имтихан алу бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Сабиров** Ирек Нуретдин улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Чаян» журналы редакциясе» баш рәссамы **Алешин** Александр Николаевичка, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Чаян» журналы редакциясе» җитәкчесе – баш мөхәррире **Хәлилуллов** Рафаэль Исмәгил улына, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Мамадыш-информ» җитәкчесе – баш мөхәррире **Ханова** Светлана Наил кызына, Буа районының кулланучылар җәмгыяте баш бухгалтеры **Хәкимова** Наилә Наил кызына, «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционер җәмгыяте» акционер җәмгыятенең 203-10 номерлы цехы шприц-машина машинисты **Әхмәтҗанова** Гүзәл Илфат кызына, «ТАИФ-НК» акционер җәмгыяте авыр калдыкларны тирән эшкәртү комплексының каты ягулык һәм күкертле нефть продуктларын гидрирлау цехы башлыгы **Карлин** Альберт Евгеньевичка, «Газпром сыекландырылган газ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Казан шәһәре газ тутыру станциясе 5 номерлы автомобильләргә газ ягулыгы салу станциясе участогы мастеры **Литвин** Александр Юрьевичка, «Авиасервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының хокук мәсьәләләре һәм администрация буенча урынбасары **Хөснетдинов** Заур Динар улына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең икътисадый үсеш комитеты шәһәр хуҗалыгын үстерү һәм электр энергиясеннән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру бүлеге баш белгече **Абрамова** Елена Николаевнага, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Шәмсетдинов** Ренат Харрас улына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге башлыгы **Гәрәева** Лилия Рәис кызына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча муниципальара бүлеге башлыгы **Барсукова** Анна Николаевнага, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы киңлек мәгълүматлары инфраструктурасы бүлеге башлыгы **Малинин** Дмитрий Александровичка, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы 1 номерлы документларны эшкәртү һәм исәпкә алу гамәлләрен тәэмин итү бүлеге башлыгы **Мирасова** Анна Алексеевнага, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Нурлат бүлеге баш белгече-эксперты **Митакова** Марина Ивановнага, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Лаеш бүлеге башлыгы **Шиһабиев** Илгиз Шәүкәт улына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге әйдәүче белгече-эксперты **Әхмәтҗанова** Гөлназ Фәрит кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының төбәкләр бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге әйдәүче консультанты **Галимуллина** Рушана Мансур кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш бухгалтеры **Гыймадиева** Сәрия Гыйльман кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Татарстан Республикасы бюджетын төзүне һәм үтәүне оештыру бүлеге әйдәүче консультанты **Хөсәенова** Алсу Нәҗип кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының цифрлы нигезгә күчеш һәм мәгълүмат системаларына хезмәт күрсәтү бүлеге әйдәүче белгече **Бандурина** Елена Вадимовнага, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының гомуми тәэмин итү бүлеге башлыгы **Бәдертдинов** Раил Бәшир улына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт милке белән эш итү идарәсе дәүләт милкенә идарә бүлеге башлыгы **Вәлиев** Илнур Рашат улына, «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыятенең 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлекчәсе кече бизнеска сату идарәсе кече бизнес клиентларына сатуны оештыру бүлегенең 8610/16 номерлы кече бизнес клиентларына сату белгечләре төркеменең кече бизнес клиентлары белән эшләү буенча әйдәүче менеджеры **Касыймов** Ришат Шәүкәт улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе хезмәткәрләре: мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Түбән Кама районара суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Абызов** Адел Айрат улына, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Алабуга районара суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Азизов** Булат Фәнис улына, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлеге табибы – суд-медицина эксперты **Биктимеров** Фиргать Хәнәфи улына, медицина-криминалистика бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты (эш урыны – Чаллы шәһәре) **Камитов** Максим Михайловичка, Чаллы филиалының мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Малинин** Алексей Владимировичка, суд-химия бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Нәбиуллин** Илдар Иксан улына, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Нурлат районара суд- медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Сатдаров** Илшат Илсөяр улына, медицина-криминалистика бүлекчәсе мөдире – табибы – суд-медицина эксперты **Сошников** Иван Александровичка, мәетләргә суд-медицина экспертизасы уздыру бүлегенең Түбән Кама районара суд-медицина бүлекчәсе табибы – суд-медицина эксперты **Шәрәфетдинов** Илнур Илсур улына, һөнәр берлекләренең дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе **«Бәкер» шифаханәсе коллективына**, «Мегаом» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гафиуллин** Раиф Нәкыйп улына, Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге башлыгы **Воляков** Николай Николаевичка, Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе **Воробьев** Виктор Николаевичка, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге башлыгы **Идиятов** Илнар Илдар улына, Татарстан Республикасының Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башлыгы **Котников** Вальтер Николаевичка, «Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары **Хәкимуллин** Рамил Фатыйх улына, Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты эшләр идарәчесе **Якупов** Марат Гайса улына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының мобилизация эше һәм дәүләт серен саклау буенча әйдәүче консультанты – белгече **Арипов** Самат Әскәр улына, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының дәүләт хезмәтен оештыру ягыннан тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе **Баязитов** Адел Әлфис улына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының оештыру ягыннан үсеш бүлеге башлыгы **Васильева** Лариса Александровнага, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты» муниципаль казна учреждениесенең эшләр идарәсе эшләр идарәчесе урынбасары **Гаффаров** Линар Рамил улына, «Татагролизинг» акционер җәмгыяте генераль директорының финанслар буенча урынбасары – аппарат җитәкчесе **Гарифуллина** Зөлфия Нургазиз кызына, «Ермолаев Андрей Владимирович» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Ермолаев** Андрей Владимировичка, «Тарасова Роза Ивановна» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Тарасова** Роза Ивановнага, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең бухгалтерлык исәбе, хисабы, икътисадый планлаштыру һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы **Филиппова** Регина Рамил кызына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының спорт инфраструктурасын үстерү һәм программаларны гамәлгә ашыру бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Самсонова** Ирина Юрьевнага, «Татарстан Республикасы Бокс федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасының бокс буенча тренеры-инструкторы **Шаяхмәтов** Альберт Әнис улына, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге әйдәүче консультанты **Юнысова** Галия Абдулкадыйр кызына, **«ТАТАР БИСТӘСЕ ПЛЮС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТАТАР

Нәсел горурлыгы

Бу нәсел хаклы рәвештә галим, профессор **Рәфыйк Әбзәл улы ГАРӘФЕТДИНОВ** белән горурлана. «Рәфыйк абыебыз – туган авылыбыз исемен Татарстанга гына түгел, бөтен илгә таныткан кеше», – диләр алар.

Үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә 1955 елда мәктәпне тәмамлаганда ук СССР халык хуҗалыгы күргәзмәсенең бронза медаленә лаек була ул. Хәрби хезмәттән кайткач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Остазлары тәкъдиме белән аспирантурада кала һәм 27 яшендә кандидатлык диссертациясе яклый. 1969 елда Казанда Ленинград дәүләт мәдәният институтының филиалы ачыла. Дәүләт җитәкчелеге ректорга ярдәмче итеп перспективалы галим Рәфыйк Гарәфетдиновны билгели. Шул ук вакытта ул фән белән дә шөгыльләнә. Санкт-Петербург шәһәренең атаклы Таврия сараенда докторлык диссертациясен яклый. 37 ел дәвамында вузда ватан һәм чит илләр тарихы кафедрасын җитәкли, вузның беренче фәнни докторы, беренче профессоры, хәтта беренче атказанган фән эшлеклесе исеменә лаек була. Ул – 200гә якын мәкалә, 10 китап авторы. 15 меңнән артык югары белемле белгеч әзерли, 20 аспирант аның кулы астында кандидатлык диссертациясе яклый, 5есе докторлык диссертациясенә алына.

ТӨП НИГЕЗДӘ

Кайбыч

«Гарәфетдиновлар туган телне, әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрне генә түгел, Кайбычның үзен саклап калдылар», – диде район башлыгы урынбасары Рамис Хәялиев, бу якларга юл тотуымның сәбәбен аңлаткач.

Менә без шушы мактаулы нәселнең төп нигезендә. Өй эче Гарәфетдиновлар белән шыгрым тулы. Әйтер сүзләре дә, күрсәтер әйберләре дә күп. Шулвакыт бер-бер артлы район башлыгы аппараты җитәкчесе, «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе, шушы төбәкне данга күмгән Галия Кайбицкая музее директоры килеп төште. Рәсми чара кебегрәк кабул иткәннәрдер инде дисәм, аларның барысы да шушы нәселдән булып чыкты. Кыскасы, Кайбычта нәрсә турында сүз чыкса, анда бу нәселнең вәкилләре я эшли, я укый, я җырлый-бии, я тагын берәр нәрсә белән шөгыльләнә икән. Зур картина итеп ясалган шәҗәрә янына басып, Рамис Хәялиев тә үз тамырларын эзләп тапты.

Өч буын

Рәфыйк Гарәфетдинов белән Шәүкәт Галиев урамнары чатында ерактан балкып торган, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән бу йортта өч буын вәкиле яши. Гарәфетдин улы Әбзәлнең төп нигездә хуҗа булып калган җиденче улы Фирдәвес абый яшьли вафат була. Тол калган Әлфия апа өч улын аякка бастыра. Шушы нәселнең ярдәмчел туганнары терәк булалар аңа. Үзе дә сер бирми. Хәзер дә эшләмәгән эше, өлгермәгән төше юк. Җыр-биюгә дә бик оста, кул эшләрен дә күз иярмәслек тизлектә башкара, бакчада үскән яшелчәләре, җиләк-җимешләренә һәркем кызыгырлык. Заманында бәйрәмнәрдә башлап йөргән, ветераннар советы рәисе булып та эшләгән ул. Хәзер дә бик чакыралар, тик ул, оныкларны тәрбиялим, дигән була.

Гореф-гадәткә тугры булып, әтисеннән алты яшьтә генә калган Фәнил дә төп нигездә оя корып җибәрә. (Әйтергә кирәк, Фаил белән Фидаил абыйлары да ерак китмәгән: берсе күршедә генә, башка чыккан, икенчесе Колаңгы авылында.) Казан мәдәният һәм сәнгать университетына укырга кергәч, китапханәчеләр әзерләү бүлегендә укучы Саба кызы Гөлсем белән таныша да гаилә корып җибәрә. Уллары Булат белән Фәрхәт мәктәптә укыйлар, кечкенә кызлары Динә «Миләшкәй» балалар бакчасына йөри.

Бу йорт ял көннәрендә генә түгел, гадәти көннәрдә дә шау-гөр килеп тора, диләр. Әйткәнемчә, Гарәфетдиновлар, һөнәрле булгач та, гаилә коргач та, Кайбычны ташлап китәргә ашыкмыйлар. Ерак бабаларыннан килгән гадәт буенча, туган як – алар өчен элек-электән изге җир. Сан ягыннан гына түгел, эш-гамәл ягыннан да алдырган нәсел бу. Эш юк дип зарланып утыручылардан түгел, булганының кадерен белеп яшиләр. Халык мәнфәгатенә бәйле зур эшләрдән дә тайчанмыйлар.

Монда яшәүче халык өчен мөһим роль уйнаган Апас районыннан аерылып чыгу мәрәкәсен дә үз җилкәләренә алганнар. Үткәннәребезне тарихка уеп калдырырга кирәк дип, китап язарга алынучылар да, иҗат белән шөгыльләнүче якташларының шигырь, хикәяләрен җыеп, туплап бирүчеләр дә – шушы нәселдән. Ә төп нигезне алар бүген дә бергәләп саклыйлар. Мәктәп, бакча, урамда нинди генә хәлләр, нинди генә яңалыклар булмасын, бу йортта рәхәтләнеп туган телдә сөйләшәләр. Башкача булуны хәтта күз алдына да китермиләр. Бу җәһәттән Әлфия апа да үз фикерен җиткерде:

– Мин күп еллар балалар бакчасында эшләдем. Заманалар төрле булды. Хәтерлисездер, 1980 нче елларда бөтен чараларны рус теленә күчерүне таләп иттеләр. Без үзебез бик ашыкмадык инде. Икесен бергә алып барырга тырыштык. Җае чыгуга яңадан татарчага күчтек. Тышкы дөньяда төрле хәлләр булырга мөмкин дип әйтәсем килә. Иң мөһиме – эчке дөньяңны какшатмаска кирәк. Үз телебездә сөйләшсәк, гореф-гадәтләрне сакласак, татарлыгыбызны һичкайчан югалтмабыз. Тарихка күз салсак, мондый каршылыклар гасырлар буена булган. Тамырыбыз нык булса, вакыты җиткәч, тышкы дөньяга ташкын булып ургылып чыга алырбыз, югалмабыз.

Сан

✓ Бүген бу нәселдә **123** кеше Гарәфетдинов фамилиясен йөртә.
✓ Олы Кайбычның Шәүкәт Галиев исемендәге урамында Гарәфетдинов фамилиясен йөртүче **5** гаилә яши.

Шәҗәрә

Гарәфетдиновлар фикеренчә, татар телен саклау, бабаларыбызның тарихын яшь буыннарга җиткерү өчен нәселнең шәҗәрә агачын төзү зур роль уйный. Быел бу гаилә үзе дә «Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең зона ярышында беренче урынны яулаган.

– Балалары, оныклары үткәннәрне онытмасыннар, татар телен белсеннәр иде дип хыялланган кешеләргә киңәшем шул, – ди Әлфия апа, – барысын да шәҗәрә белән кызыксындырырга кирәк. Безнең балалар бакчасында аз дигәндә 3–4 буынны белмәгән бала бик сирәк. Әти-әниләре ярдәме белән ясап килгән картиналарын стенага элеп куя идек. Шунда килерләр иде дә үзара: «Менә минем шундый туганым бар, бу бабам Бөек Ватан сугышында булган, әбиемнең бүләкләре әнә нихәтле», – дип, горурлана-горурлана сөйләрләр иде. Татарча сөйләшкән әби-бабасы турында бала гадәттә шул телдә сөйли. Шулай тиеш дип белә. Белгәнемчә, бүген дә дәвам итә бу эш, бакчадан аннан мәктәпкә күчә, безнең кебек шәҗәрәләр төзеп зурдан кубучылар да бар.

Әлфия апаны җөпләүчеләр күп булды. Кайбыч мәктәбендә, гомумән, шәҗәрә фестивальләре үткәрелеп килә икән. Җиңүчеләр республика ярышларында катнашалар. Фестивальләр үткәрелгәндә, Кайбычта яшәүчеләр генә түгел, еракларга киткән туганнар да күтәрелә. Шулай итеп бердәмлеккә нигез салына.

Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем. Бу нәселдә буыннан буынга, нигездә, гел малайлар туа. Кызлар бармак белән генә санарлык. Бу хәлгә үзләре дә гаҗәпләнәләр. «Безгә шушы Кайбыч җирен саклап калу миссиясен үтәргә кушылгандыр инде», – дип көлешәләр.

Табын күрке

Китапханәдә эшләп, Кайбыч халкына аң-белем эстәүче, төп нигездәге яшь килен, ягъни уллары Фәнилнең хәләл җефете Гөлсем белән аш-су турында сөйләшәбез.

– Әниебез безне, татар гаиләсенә хас булганча, кечкенәдән тәмле татар ризыклары пешерергә өйрәтеп үстерде. Шуңа күрә бу йортка килен булып төшкәч тә авырлыгын тоймадым, – ди ул. – Ял саен әни белән төрле ризыклар әзерлибез: пироглар да, пәрәмәч тә, кош теле, чәкчәкләр дә калмый. Төп нигез булгач, күрешергә дип туганнарыбыз да күп килә. Сыйланабыз. Шулай да мин гөбәдияне татар табынының күрке итеп күрәм. Өстәл тирәли туганнар тезелеп утырганда аны чыгаруы да – үзе бер затлы күренеш. Бәйрәмчә, үзебезчә була. Мактый-мактый ашыйлар. Юкка гына түгелдер. Рецептын укучыларыбызга да тәкъдим итим әле.

ГӨБӘДИЯ КАМЫРЫ

2 йомырка, 1 стакан сөт, 2 аш кашыгы шикәр комы, 1 чәй кашыгы тоз, 1 чәй кашыгы чүпрә, 1 аш кашыгы майонез, 4 аш кашыгы эретелгән атланмай, кирәгенчә он.

ЭЧЛЕК ӨЧЕН

Корт (кызыл эремчек), 1,5 стакан дөге, 1 стакан йөзем җимеше, 2 йомырка, 12 аш кашыгы атланмай.

Сөтне җылытып, камырга барлык әйберләрне бергә салып, шикәр комы, тоз, чүпрә эреп беткәнче болгаталар. Иләнгән онны әз-әз кушып, йомшак кына итеп камыр басалар.

Камыр кабарганчы эчлек әзерләнә. Эчлеккә дөге бүрттерәбез (аны бүрткәч, салкын су белән йөгертәбез), йөземне чистартып, юып киптерәбез, йомырка пешереп, вак итеп турыйбыз. Иң беренче табаны майлап, камырны бик калын итмичә җәеп табага салгач, корт (кызыл эремчек) салабыз, икенче эш итеп бүрттерелгән дөгене, аннан дөге өстенә йөземне салабыз, дүртенче катка туралган йомырканы салабыз да бераз гына шикәр комы сибеп чыгабыз. Һәм соңгы эш итеп эретелгән 12 аш кашыгы атланмайны агызабыз. Өстен юка гына җәем камыр белән каплап, 200–220 градуслы духовкада 30–35 минут пешерәбез. Ашларыгыз тәмле булсын!

ЮКА

Кирәк: *1 литр сөт, 7 данә йомырка, 250 г сыек май, 100 г чүпрә, он, 1 чеметем тоз, шикәр комы.*

Җылытылган сөткә шикәр комы, чүпрә, йомырка, май, тоз, он кушып, камыр басабыз. Камыр әзер булгач, кисәкләргә бүлеп, 3–4 см калынлыкта түгәрәкләп җәябез. Әзер түгәрәкне җылытып майланган табага салабыз да утка куябыз. Юка пешерер өчен духовканың өске уты да, аскы уты да янарга тиеш. 8–10 минуттан юкалар әзер була. Аларны зур куна тактасына берәм-берәм тезә барабыз. Ашыгыз тәмле булсын!

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 298

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+